


Яшәсен туган як күңелләрдә һәр чак,
Юлларың яктырткан нур булып.

Резеда Вәлиева.

# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 4 (7) АПРЕЛЬ 2009

НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

## Расширенное заседание Совета ТНКА

22 апреля в селе Асекеево, в Доме культуры состоялось расширенное заседание Совета татарской национально-культурной автономии района. На нем, с обширным отчетным докладом о проделанной работе, о проблемах и задачах ТНКА, выступил председатель Совета Ильдус Давлятов. В обсуждении доклада приняли участие члены Советы ТНКА, педагоги и работники культуры.

В работе Совета приняли участие и выступили: глава администрации Асекеевского района Николай Макаров: заслуженный деятель искусств Татарстана, поэтесса Резеда Валиева. Тезисы доклада И. Давлятова публикуются на второй странице газеты.

## Подворью быть

В скором времени, в Оренбурге, в «Национальной деревне» откроется татарское подворье. Постройки, внутреннее убранство будет рассказывать о быте татарского народа, традициях и культуре.

## Правовой нигилизм наносит вред национальным интересам народа

**Заявление бюро Исполкома Всемирного конгресса татар**

В последнее время в средствах массовой информации появились сообщения о создании так называемого татарского правительства в изгнании. Абсурдность возникшей ситуации очень точно отражает крылатое выражение «благими намерениями вымощена дорога в ад». Дело в том, что создание такого правительства означает фактическое отрицание существующей государственности татарского народа в лице Республики Татарстан. При всех издержках становления государственности Татарстана на последних двух десятилетий, необходимо признать один непреложный факт: сегодня невозможно представить друг без друга татарский мир и Татарстан. Это огромное достижение национальной общественности и народа Татарстана. Мы гордимся, что свой достойный вклад в дело консолидации татарского мира и Татарстана вносит Международный союз общественных объединений «Всемирный конгресс татар». Будучи зарегистрированным в Министерстве юстиции РФ, он действует на основе Устава, руководствуясь конституционными положениями, законодательством РФ и РТ, нормами международного права.

## Мин татарча сөйләшәм

В рамках акции «Мин татарча сойлэшэм!» («Я говорю по-татарски!»), которая проходит сейчас в Татарстане, лидеры татарской молодежи планирует выступить с законодательной инициативой предания татарскому языку второго государственного в России. Как сообщил info-islam.ru председатель Бюро Всемирного форума татарской молодежи Руслан Айсин, сейчас идет сбор подписей по всей России под обращением, предлагающим официально признать татарский язык вторым государственным языком в России. Как отметил Руслан Айсин в рамках акции «Мин татарча сөйләшәм!», решено принять программу под названием «Татарский язык — язык мира и матери». Данная программа нацелена на то, чтобы повысить статус татарского языка на федеральном уровне.

**(С интернет ресурса Всемирного Конгресса татар)**

ЯҢАЛЫКЛАР

## Җыр яңгырый, моң яңгырый

Милләт язмышы, мәхәббәт дөньясы, халык моңы аша буыннан буынга сакланып килгән олы мирас.

Бөек Тукаебыз васыять итеп калдырган:

— Халык җырларының шулай җәүһәр вә яхутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһат итәргә кирәк, — дигән сүзләр бүген дә бик заманча яңгырыйлар.

Бу изге бурычны беренче халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсы Татарстан мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар когрессы, Яна Гасыр телерадиокомпаниясе оештырган фестиваль быел үтәде дип әйтсәк була.

Конкурсның комиссия әгъзалары ярты ел буенча яшь җырчыларны төрле төбәкләрдә сибелеп яшәүче татар халкы арасыннан сайлады. Сайлау 3 тур аша үткәрелде. Өч меңгә якын җырчыларны тыңлап комиссия гала-концертка 20 — җырчыны үткәрде.

Шулар арасында Оренбург өлкәсеннән безнең Виолетта Валишина 3 турдада җиңүче булып Муса Җәлил исемендәге опера балет театры сәхнәсендә 4 апрельдә "Ай йолдызым" җырын җырлады. Бу концертта яшь башкаручылар белән бер сәхнәдә халкыбызның танылган җырчылары да чыгыш ясадылар: Мәскәүдән — Алсу Сафина, Казаннан — Миңгол Галиев, Салават Фәтхетдинов.

Безнең Әсәкәй йолдызын Казан тамашачысы яратып алкышлады. Виолетта татар халык җырларын оста башкарганы өчен махсус дипломга, конкурсның көмеш бүләгенә лаек булды һәм тагын чәчәк бәйләме белән кыйммәтле бүләк алды.

Киләчәктә без аңа моң дарьясы саекмавын теләп калабыз.



**Гүзәл Калимуллина, Әсәкәй район мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе.**

**Фотода:** Виолетта татар дәүләт ансамбле биючеләре белән.

## Бөек Тукай аенда очрашу

"Бердәмлек" ассоциясенең беренче "карлыгачы" булып халкыбызның мәңгелек нуры булган Тукаебыз әсәрләреннән торган төбәкара конкурс Гали авылы Самара өлкәсендә булды.

Конкурс номинацияләре: нәфис сүз, рәсем, җыр, бөек шагыйребез тормышына багышлаган сочинение.

Самара өлкәсе авыллары һәм безнең Әсәкәй районы Яңа Солтангол һәм Тамьян авылларыннан балалар катнашты.

Тукай мирасын беренче класстан алып 11 класс укучылары Гали авылы мәдәният йорты сәхнәсендә зур осталык белән сөйләделәр.

Балаларның чын күңелдән туган телебезне шагыйрнең тирән мәгънәле әсәрләре аша яңгыратуы залда утырган тамашачыларның күңелен әсир итте.

Жюри һәрбер номинация буенча беренче, икенче һәм өченче дәрәҗә дипломнары билгеләде. Жюри рәисе Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Резеда Вәлиева конкурсантларны котлап дипломнар һәм бүләкләр тапшырды. Беренче дәрәҗә дипломантлары аның "Күңелем гөлләре" дигән шигырләр китабы белән бүләкләнде.



Татар халкының данлыклы танылган шагыйрәсе үзенең Тукайга багышланган һәм киң таралган берничә шигырен башкарды сәхнәдән. Аның ялкынлы чыгышы балалар күнелендә һәм олы яшьтәге тамашачылар йөрәгендә олы Тукаебызга булган ихтирамны тагы да көчәйтте.

Конкурста нәфис сүз номинациясендә безнең район кызы Яңа Солтангол авылыннан Эльза Бакирова беренче урынга лаек булды. Ул Г. Тукайның "Су анасы" шигырен укыды.

Безнең районда "Туган тел" клубы быел да Тукай әсәрләренә багышланган очрашулар үткәрде. Бу очрашуларның ин күркәм бизәге Татарстаннаң килгән Резеда апа Вәлиева чыгышлары булды.

Ул Яңа Солтангол авылы укучылары һәм укытучылары өчен Тукай турында язылган шигырьләрен сөйләде. Балаларга аның әсәрләренең тирән мәгънәсен аңлатты. Шулаюк Әсәкәйдә 22 апрельда Тукайга багышланган Резеда Вәлиева катнашуында очрашу-концерт булды. Укучыларга Резеда апа автографлы китапларны бүләк итте.


**Зәйтүнә ВАЛИШИНА.**

**Фотода:** Эльза Бакирова.

ОФИЦИАЛЬНО

# Тезисы

## Отчетного доклада председателя Совета татарской национально-культурной автономии Асекеевского района И. ДАВЛЯТОВА



Уважаемые земляки, друзья! Нынешний состав Совета национально-культурной автономии работает с 12 апреля 2007года, после избрания на очередной отчетно-выборной конференции. За этот период было проведено 12 заседаний совета. Работа ведется согласно утвержденным планам и в соответствии с пожеланиями, высказанными на конференции.

Основной задачей Совета стало создание первичных организаций автономии на местах, для выявления проблем волнующих сельчан и их решения. «Первички» были созданы в селах Новосултангулово, Кисла, Старокульшарипово, Старомукменево и поселке Чкаловский. Они сейчас успешно работают.

Большим испытанием на прочность и работоспособность для нового состава совета стала организация и проведение областного фестиваля татарской культуры «Сабантуй», который прошел 23 июня 2007 года в селе Асекеево. Была проведена громадная работа и праздник удался на славу. Высокую оценку Сабантую дал председатель Законодательного собрания Оренбургской области Дмитрий Кулагин. В частности, он сказал, таким форумом можно только гордиться.

Ежегодно, в летний период, совет автономии направляет детей нашего района в Татарстан, в лагеря активного отдыха. В лагерях предусмотрен не только отдых. Происходит ознакомление подрастающего поколения с историческим и культурным прошлым татарского народа, организуется обучение родному языку. Ежегодно профильную смену посещают около 30 детей. В этом году смена также будет проводиться в два потока. Первый поток с 11 по 26 июня, стоимость путевки 3500 рублей, и второй поток с 20 по 31 июля, стоимость путевки 3000 рублей. Сейчас формируются списки желающих отдохнуть в лагерях.

Организовывались экскурсии в Казань и для взрослых. Делегацию отбирали открыто, поехали все желающие. Была возможность посетить исторические места, музеи. С нашей делегацией встретился председатель исполкома Всемирного Конгресса Татар Ринат Зиннурович Закиров. Главное, после этих мероприятий у людей не осталось горького осадка, что в Казань едут одни, скажем так, “приближенные” к руководству ТНКА. Люди приехали очень довольные.

Уважаемые ветераны — аксакалы смогли летом 2008 года посетить древнюю столицу татар Булгар, для них был бесплатно предоставлен комфортабельный автобус

Ежегодно мы участвуем во Всемирном Форуме татарской молодежи в г. Казани. Он проводится с целью объединения татарской молодежи и приобщения ее к ценностям национального духовного наследия, формирования национального самосознания у молодого поколения татар.

Наша солистка районного дома культуры “Романтика” Виолетта Валишина принимала участие в Международном телевизионном конкурсе молодых исполнителей “Татар моны”. Она успешно прошла все отборочные туры и выступила в заключительном гала-концерте в Казани, стала дипломантом престижного конкурса.

Есть возможность у наших детей и обучатся на бюджетной основе в Татарстане, в различных учебных заведениях. Так, в прошедшем году выпускник Асекеевской средней школы Айрат Нугуманов по нашему направлению поступил в Казанский технологический университет. Надеемся, что и в этом году нам вновь предоставят квоты для выпускников школ.

20 октября 2008 года делегация нашего района из пяти человек приняла участие в Четвертой конференции Оренбургской региональной татарской национально-культурной автономии. Делегаты конференции с интересом выслушали О.Ю. Сулюкманова, председателя первичной организации ТНКА из Старокульшарипова, который поделился своим опытом.

12 — 16 декабря 2008 года в г. Казани проводился 4 съезд Всемирного конгресса татар, делегатом от нашего района был И.Я. Давлятов.

Заметным событием в жизни нашего района и области стали дни татарской культуры, которые проводились 2 — 3 февраля 2008 года в Районном Доме Культуры “Романтика”. Так, 2 февраля, состоялось творческая встреча с писателем, заслуженным деятелем Татарстана, обладателем премии “Хрустальное перо” Союза писателей республики, журналистом татарского радио “Азатлык” (Свобода) Назифой Каримовой и заслуженной артисткой Татарстана, солисткой Московской филармонии Розой Хабибулиной. Такая же встреча проводилась и в этом году. В ней, наряду с Назифой Каримовой, приняла участие Заслуженная артистка России и Татарстана Наиля Фатехова.

Большим событием в жизни района и области стало ежегодное проведение фестиваля “Ак хисляр” (Светлые чувства). В этом году он проводился уже в пятый раз. Фестиваль областного значения, а теперь уже межрегиональный. Авторитет фестивалю придает и жюри, которое возглавил народный артист Татарстана, доцент музыкального факультета Казанского государственного педагогического университета Мингол Галиев.

Таким же большим событием в жизни района является фестиваль “Алтын Көз”

Ежегодно проводиться районный праздник “Науруз”, в рамках которого в 2008 году к нам приезжали сотрудники знаменитого татарского журнала “Сиюмбикә” Фирая Бадретдинова — главный редактор, Гульнур Сафиуллина — корреспондент, начальник информационно-аналитического отдела Всемирного конгресса татар — Гульназ Шайхи и народный артист Татарстана — Фердинанд Саляхов.

Благотворное влияние на духовную жизнь нашего района оказывают и тесные связи с деятелями культуры Татарстана. На постоянной основе проходят гастрольные концерты именитых артистов Татарстана, Башкирии и Оренбурга. Такие звезды, как Салават Фатхетдинов, Хания Фархи, Гузель и Ильдар Уразовы, Шахбан, Асылъяр и многие другие показали свое высочайшее искусство на Асекеевской сцене.

Продолжаются работы по благоустройству памятника поэту, герою Советского Союза, Мусе Джалилю.

Оказана спонсорская помощь в издании книг на татарском и русском языках нашей землячке из Старомукменева Гульнур Гареевой, члену Нижнекамского литературного объединения

В октябре 2008 года вышел первый номер общественно-просветительной газеты «Туган як. Родной край». В декабре 2008 года газета официально зарегистрирована и вошла в каталог СМИ Российской Федерации. Учредителем газеты стала ТНКА. Газета выпускается и распространяется в 6 районах северо-запада нашей области. Сейчас ведутся работы по организации подписки. Газета пока выпускается один раз в месяц.

Знаменательное событие произошло 13 марта 2009 года в Бугуруслане. В Доме Культуры имени Тукая состоялось подписание Декларации о создании межрегиональной Ассоциации татарских национально-культурных объединений «Бердәмлек». Пока в Ассоциацию вошли три объединения: ТНКА Асекеевского района, татарский общественный центр “Туган тел” г. Бугуруслана, и культурно-просветительное общество “Туган тел” из с. Алькино Похвистневского района.

Все три объединения согласовали планы по культурно-просветительной работе на ближайший период.

Но, в нашей деятельности достаточно и проблем. Сейчас в Асекеевской средней школе преподавание татарского языка ведется только в 9 классе, в нескольких других классах только факультатив.

И виной тому не руководство управления образования, а сами родители, которые не желают, чтобы их дети учились родному языку. Это в корне не правильно, когда самым ненужным предметом становится родной язык. В остальных школах в татарских селах преподавание татарского языка ведется на должном уровне.

Также обучение родному языку ведется и в дошкольных учреждениях с. Асекеево и в с. Новосултангулово.

На базе Асекеевского детского сада №4, 24 октября 2008 года проводился межрегиональный семинар по теме “Инновационные образовательные технологии в практике работы учреждении дошкольного и начального образования по приобщению детей к этнокультуре родного народа”. В работе семинара приняли участие, как представители области, так и методисты из Татарстана — городов Бавлы и Бугульма. Наши гости показали мастер класс по применению инновационных технологий.

Надо отметить, что на научно — практическом семинаре царила атмосфера доброжелательности и доверительности.

Семинар вызвал живой интерес и благоприятные отзывы не только у руководителей, учителей и воспитателей, но и у специалистов Министерства образования Оренбургской области.

Проблем конечно много, они есть везде, их надо решать. Решение вышеперечисленных проблем требует организованной и совместной работы всех членов Совета.

**На снимке:** юные школьницы — Настя Скала и Алия Закирова, читают перед участниками заседания Совета ТНКА стихи Г.Тукая, на татарском языке. Еще один довод, в пользу интернационального воспитания детей.

ГОСТИ ИЗ КАЗАНИ

# Приглянулся наш край

**Известной поэтессе Резеде ВАЛИЕВОЙ полюбился наш край. Она уже во второй раз приезжает к нам и ее тепло встречают наши земляки, восторженные творчеством Резеды апы. Возможно, в скором времени, у нее появятся стихи, посвященные нашему краю, нашим людям. Впрочем, такие стихи уже есть.**

**Әсәкәйнең уңган егете, хөрмәтле Сәет Бәшир улы Гизитдиновка багышлыйм.**

Ниләр белән котлыйм бүген сине,
Бакчалардан гөлләр өзимме.
Әллә хисләремне җырга салып,
Энҗе-мәрҗән итеп тезимме.

Җырлар юллыйм әле, алар миннән
Бер истәлек булып калсыннар.
Теләкләрем гомер юлларында,
Дога булып озатып калсыннар.

Күрегезче, көзге бу көн җиргә,
Нинди гүзәл кеше китергән.
Әнкәсе дә назлап бозмаган һич,
Уңган егет итеп үстергән!

Өйрәткәннәр яшьли эш сөяргә,
Туган җирен хөрмәт итәргә.
Үз алдына зур максатлар куеп,
Акыл белән дөнья көтәргә.

Якты акыл белән кайнар йөрәк
Ир-егеткә мәңге зур терәк.
Акыллы да бит син, бик уңган да,
Бәхет өчен тагын ни кирәк?!

Якты акылың, саф күңелең белән
Яшәү ямен аңлый беләсең.
Бәхет кенә теләп кешеләргә
Игелекләр белән киләсең.

Шуңа бүген хөрмәт иясе син,
Ир уртасы, дөнья терәге.
Кабул итеп алчы бәйрәмеңдә
Дусларыңның кайнар теләген:

Озак яшә, мәңге бәхетле бул,
Ишегеңне кайгы какмасын.
Картлык каһәр, эзләп хәлдән тайсын,
Адресыңны мәңге тапмасын!

Һаман шулай уңган һәм җитез бул,
Ялкаулыкны җаның белмәсен.
Сәламәт бул һәрчак, таза-сау бул,
Һичбер сырхау якын йөрмәсен!

Йортың тыныч булсын, табыннарың
Сый-хөрмәттән сыгылып торсыннар.
Бәгърең исән булсын, балаларың
Ярларыннан егылып уңсыннар.

Үткәннәрең матур, киләчәкләр
Үткәннән дә матур булсыннар.
Таңнарың гел балкып тусыннар.
Озак яшә!

**КАЗАН. 2009 ЕЛ.**

НАШИ СОСЕДИ



# Гали авылы — значит Алькино

**Откровенно говоря, желание побывать в Алькино соседнего, Похвистневского района, появилось после прочтения статьи, о визите в это село министра сельского хозяйств Татарстана.**

**Вот эти строки:**

«В большинстве алькинских подворий сейчас специализируются на круглогодичном тепличном выращивании помидоров и огурцов. Как рассказал глава администрации села Идрис Муллабаев, суммарный доход жителей Алькино от этого вида деятельности составляет 90-95 млн. рублей в год. Такой подход очень заинтересовал соседей из Татарстана. Четырнадцатого апреля в Алькино высадился десант гостей из соседней республики... Министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан Марат Ахметов, возглавивший делегацию, привез с собой 10 руководителей сельских районов Татарстана, перед которыми теперь стоит задача внедрить опыт Алькино на подведомственной им территории. Показать в Алькино есть что. При населении около двух тысяч человек в селе держат 468 теплиц общей площадью 250 га. Кроме того, жители села выращивают раннюю морковь и лук-севок, за которым приезжают даже из других областей. Доход средней семьи в Алькино от ведения ЛПХ составляет порядка 600-700 тысяч рублей в год. Но при этом селяне деньги стараются не копить, а тратить на строительство, обустройство и обучение детей в ВУЗах. Нет проблем у жителей Алькино и с транспортом. В селе сейчас около тысячи машин, а меняют автомобили жители каждые 3-4 года. Своеобразно решена здесь проблема с алкоголем — три года назад жителями было принято решение о запрете продажи водки в местных магазинах, и теперь ее можно купить только в одной точке продаж. Правда, шутят жители, на спиртное времени все равно нет, поскольку оно уходит на работу. Не забыто и такое направление, как откорм скота. При этом проблем с реализацией мяса нет — в селе есть собственное перерабатывающее предприятие, которое выпускает 27 видов колбас, 15 видов полуфабрикатов и 4 вида консервов...».

**(РИА Самара. www.riasamara.ru).**

Надо добавить, что продукцию в селе выпускают халяльную — дозволенную для мусульман.

Но не только сельским подворьем живы алькинцы. Здесь много внимания уделяется развитию национальной самобытности народа, поддержке традиций культуры, языка и веры. Действует несколько мечетей. В Доме культуры в день нашего визита проводился конкурс среди детей, посвященный дню рождения Габдуллы Тукая. Ребята очень старались в постановках по произведениям Тукая и в чтении стихов поэта. Очень интересным был конкурс рисунков.

Если говорить о селе, то здесь прекрасная трехэтажная школа, улицы ровные, дома крепкие, красивые. Дворы и палисадники чистые ухоженные. Сразу видно, народ живет здесь работящий, толковый. Уверен, что это будет не последний рассказ о замечательном селе Гали -авылы.

**Г. ФАТТАХОВ.**

МИЛЛИ ТӘРБИЯ

# Белем һәм тәрбия бирүдә Ризаэтдин Фәхретдин мирасы

**Күренекле галим һәм фикер иясе Ризаэтдин Фәхретдиннең тууына 150 ел тулуга багышлана.**



Бүгенге көндә тәрбия, әдәп — әхлак мәсьәләләре купләребезне борчый. Кая барабыз? Урлашу, алдашу, үтерү гадәти күренешкә әверелеп бара. Тир түкми генә байлык туплау — төп кәсепкә әйләнде, наркомания, җинаятьчелек, эшсезлек чәчәк ата. Яшьләрнең күбесе ак белән караны аера алмый, күңеле белән акчага, шул исәптән хәрам малга алданып бара. Гасырлар буена буыннан — буынга күчеп килгән намуслылык, шәфкатьсезлек, бер — береңә ярдәм итү, эчкерсезлек, саф мәхәббәт, үз ихтыяҗыңны башкаларныкыннан өстен куймау кебек әхлакый хәзинәләр аяк астына таптала, онытыла башлады.

Татар халкы тарихында тирән эз калдырган галимнәребез әсәрләренә соңгы елларда зур игътибар итәбез.

Бүгенге көндә Ризаэтдин Фәхретдиннең мирасын барлау — белем, тәрбия өлкәсендә алыштыргысыз ярдәмчебез.

Олуг мәгърифәтче халыкка кире кайтты, аның әсәрләренә соңгы елларда игътибар итә башладык. Аның иҗатына багышланган фәнни — гамәли конференцияләр, педагогик укулар оештырыла.

Тәрбия темасына багышланган дәреслекләрендә Ризаэтдин Фәхретдин:"Яшь буынны тәрбияләү эше — ул бик мөһим социаль мәсьәлә һәм ул үзенә укучыларның вә ата-аналарның даими игътибарын таләп итә ", — дигән фикерне әйтә. Ул җанытәне белән чын күңелдән шуларны аңлатырга тырышып яши. Мәгърифәт һәм белем тарата: әдәби һәм био-библиографик хезмәтләрендә тормышны реалистик карашлардан чыгып бәян итә. Аңарда акыл һәм белемнең чикләнмәгән көченә ышану, мәгърифәтне ялкынлы пропагандалау, үстерү нәтиҗәсендә үз халкын бәхетле итәргә омтылу хас. Галимнең язган барлык хезмәтләрен бергә җыйсаң, саллы бер энциклопедия тәшкил итәр иде.

Киң карашлы мәгърифәтче һәм педагог буларак, Ризаэтдин Фәхретдин яшь буынның милли аңын һәм культура дәрәҗәсен үстерүне алгы планга куя. Аның хезмәтләре балаларны кешелекле, инсафлы, әдәпле, әхлаклы булырга өйрәтә. Бүгенге мәктәп-гимназияләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләренең төп вазифалары да шул.

Мин Әсәкәй районы Әсәкәй авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытам. Максатым: халык педагогикасы нигезендә укучыларга милли үзаңлы һәм бар яктан камил шәхес формалаштыру. Ризаэтдин Фәхретдин мирасын барлау, өйрәнү максатында үзем даими эзләнү эшләре алып барам. Аның хезмәтләрен дәресләрдә файдаланам. Күренекле галим һәм язучы Риза Фәхретдиннең әдәби — гыйльми эшчәнлеге 19 йөзнең азагы 20 нче гасырның башына туры килә. Сыйныфтан тыш уку, өстәмә дәресләр хисабына Ризаэтдин Фәхретдиннең иҗатын укучыларга тирәнрәк өйрәтергә тырышам. Татар теле һәм әдәбияты кабинетындагы күчмә стендларда һәр сыйныф өчен атна саен нәсихәтләр тупланыла һәм өйрәнелә. Бөек галимебез мирасын өйрәнү максатында класс сәгатьләре үткәрәм. Риза Фәхретдиннең дөньяга карашындагы үзенчәлекләрне ачыклаганда миңа" Мирас ", "Казан утлары " ," Мәгариф " журналлары," Татар әдәбияты тарихы" китабы, галимнең кызы Әсма Шәрәф истәлекләре ярдәмгә килә. Мәшһүр галимебезнең һәр әсәре, һәр нәсихәте әхлак кануннарына, миллилектә, мәгърифәткә мәхәббәт тәрбияләүдә алыштыргысыз мирас.

"Балаларны изге итү юлы ничек? Аның юлы исә яшь вакытлардан башлап, яхшы тәрбия бирүдер. Бу эш ата һәм ана өстендә иң олы бурыч", — ди бөек педагог үз хезмәтләрендә.

Без укучылар өчен генә тәрбияче түгел, ә бәлки әти-әниләрне дә тәрбияләргә тиешле.

Бу максаттан чыгып, әтиәниләр өчен Риза Фәхретдиннең нәсихәтләре буенча класс җыелышлары үткәрү һәм хезмәтләреннән даими файдалану, класстагы аңа багышланган почмакларны тулыландыру эшенә аларны да тарту — олы нәтиҗәләр бирә. Чөнки тәрбияле әти-әни генә тәрбияле бала үстерергә мөмкин. Чыннан да, бала иң беренче тәрбияне ата-ана үрнәгендә ала бит.

"Тәрбияле аналар балаларны үзләре тәрбия итәрләр, мөмкин кадәр икенче кешегә тапшырмаслар. Чөнки баланы үз анасы кадәр һич кем тәрбия итә алмас".

"Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз".

Ризаэтдин Фәхретдин үзенең әсәрләрендә милләтне аң-белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар бирә." Сәлимә, яки гыйффәт "," Әсма ", яки "Гамәл вә җәза" повестьлары моңа мисал булып тора. Яшьлегендә ата-анадан яхшы тәрбия алганнар, тормыш пычракларыннан кер дә кундырмыйча саф килеш калып, бәхеткә ирешә. Риза Фәхретдин фикере шундый. Аның тәрбиягә кагылышлы "Тәрбияле бала ", " Тәрбияле ата ", " Нәсыйхәт " кебек җыентыклары — мөгаллимнәр өчен чын табыш.

Татар теле дәресләрендә" Тәрбияле бала " әсәреннән җөмләләрне карточкаларга язып кулланырга була.

"Тәрбияле бала бетмәс хәзинә булса, тәрбияле булмак бик җиңелдер".

"Ата вә ана өчен тәрбияле бала дәрәҗәсендә олуг байлык һич булмас" һ. б. Бу очракта укучыларга төрле грамматик биремнәр биреп, соңыннан җөмләләргә таянып, тәртип, әдәп турында әңгәмә оештыру отышлы була.

Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәткә киң сәләтлелек һәм күпьяклы эшчәнлек хас. Гаделлек принципларына корылган җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларны Р. Фәхретдин халыкны тәрбияләүдә күрә. Ул иң әүвәл укытучы-тәрбияче булуы белән данлыклы, чөнки ул хезмәтен укытучы буларак башлый һәм тәрбия өлкәсендә яңалыклар, шул исәптән яшүсмерләргә дөньяви фәннәр укытуны кертеп, үзен алдынгы педагог буларак таныта.

Безнең буынның өмете — киләчәк яшьләребез. Максат — татар яшьләренең тотрыклы, иманлы булуы. Бер-беребезгә әдәпле, ихтирамлы, шәфкатьле булыйк. Шул вакытта гына үзебезгә әдәпле, милли үзаңлы, яхшы алмашчылар әзерли алабыз.

"Без бетә торган кавем түгел, бәлки дөньяда мәңге торыр вә башка милләтләр бергә берлектә җир йөзеннән файдаланыр өчен килгән милләтбез" дип язды Р.Фәхретдин. Милләтне яшәтерлек буын тәрбияләү һәрберебезнең изге эше, бурычы. Бөек шәхесне без генә түгел, киләчәк буын да онытмасын, аны өйрәнсен, аның хезмәтләрен кулланып һәм аның белән горурлансын иде!

"Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән милләт үткән көннәрне белсен һәм үз тарихы белән дус булсын иде", — дип бөек мәгърифәтчебез ялгышмагандыр дигән теләктә калам.

**Нәзимә АТАЛЫЙКОВА,**
**Әсәкәй урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**

# Әни-этиләргә!

Мин бүген сезгә әйтәсем килә
Әнкәм һәм әткәм турында.
Сезгә рәхмәт әйтәсем килә
Мин якты дөньяга тудырганга.

Сезнең бер — берегезне ячратканга,
Мин барлыкка килдем бу дөньяга.
Сез мине үстердегез яратып,
«Сөеклем, аппагым!» — диеп.

Рәхмәт сезгә белдерәм яратып!
Сез минем әнием һәм әтием!!!
Төннәр йокламый мине сөйдегез,
Чирләгәндә янымнан да китмәдегез.

Һәрбер шатлыкка бергә шатландыгыз,
Көн дә мине сөендердегез.
Үскәндә мин бер дә сизмәдем,
Ничек сезгә кыен булганын.

Мин сезнең чәчкәгез идем.
Бүген дә мин сезгә сокланып карыйм.
Әнкәем һәм әткәем!
Сез миңа балачакта биргән бәхетне,
Мәңге онытмам!!!

Мин сезгә, әнкәем — әткәем,
Бүген дә "балакаем"!
Бөтен дөнья чәчкәсен җыйсам да,
Минем сезгә җитмәс бүләгем!

Сезнең миңа биргән йөрәк көчең өчен,
Рәхмәтләр сезгә укыйм!!!

# Туган як

"Туган як, туган як," —
Дип җырлыйлар җырчылар.
Мәгънәләрен аңлыйлар микән алар?
Әллә барсыда авылда
Туып үстеләр микән алар?

Туган ягымы сагынганда,
Әсәкәй районы искә төшә.
Кызыл тау асларына
Йөгереп кайтасы килә.

Матур яшел болыннарына
Кайтасым килә минем:
Әсәкәй, Карамал,
Колшәрип, Тамьян якларына,
Солтангол сабантуйларына.

Гөрләп тора ул вакытта,
Һәрбер гаилә дә,
Тавык ашы һәм көлчә
Яңа пешкән авыл печендә.

Хисләр мине кайтара
Бәхетле балачакка.
Минем искә төшә печән вакыты,
Болындагы җиләк исе.

Ничек кенә мин сине яратам —
Туган ягым,
Рәхмәт сина — туган ягым!!!
Минем әни һәм әти ягы!!!
Мин сине мәңге онытмам!!!

**Раниль ШАЙДУЛЛИН.**
**с.Старокульшарипово.**





# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

(время местное)

| Май | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-56 | 6-56 | 15-10 | 20-04 | 22-04 | 23-34 |
| 2 | 5-54 | 6-54 | 15-10 | 20-06 | 22-06 | 23-36 |
| 3 | 5-52 | 6-52 | 15-10 | 20-08 | 22-08 | 23-38 |
| 4 | 5-50 | 6-50 | 15-10 | 20-10 | 22-10 | 23-40 |
| 5 | 5-48 | 6-48 | 15-10 | 20-12 | 22-12 | 23-42 |
| 6 | 5-46 | 6-46 | 15-10 | 20-13 | 22-13 | 23-43 |
| 7 | 5-44 | 6-44 | 15-10 | 20-15 | 22-15 | 23-45 |
| 8 | 5-42 | 6-42 | 15-10 | 20-16 | 22-16 | 23-46 |
| 9 | 5-40 | 6-40 | 15-10 | 20-18 | 22-18 | 23-48 |
| 10 | 5-38 | 6-38 | 15-10 | 20-20 | 22-20 | 23-50 |
| 11 | 5-36 | 6-36 | 15-10 | 20-21 | 22-21 | 23-51 |
| 12 | 5-34 | 6-33 | 15-10 | 20-23 | 22-23 | 23-53 |
| 13 | 5-32 | 6-31 | 15-10 | 20-25 | 22-25 | 23-55 |
| 14 | 5-30 | 6-30 | 15-10 | 20-26 | 22-26 | 23-56 |
| 15 | 5-29 | 6-29 | 15-10 | 20-28 | 22-28 | 23-58 |
| 16 | 5-28 | 6-28 | 15-10 | 20-30 | 22-30 | 24-00 |
| 17 | 5-26 | 6-26 | 15-10 | 20-32 | 22-32 | 24-02 |
| 18 | 5-24 | 6-24 | 15-10 | 20-34 | 22-34 | 24-04 |
| 19 | 5-23 | 6-23 | 15-10 | 20-35 | 22-35 | 24-05 |
| 20 | 5-21 | 6-21 | 15-10 | 20-37 | 22-37 | 24-07 |
| 21 | 5-20 | 6-20 | 15-10 | 20-38 | 22-38 | 24-08 |
| 22 | 5-18 | 6-18 | 15-10 | 20-40 | 22-40 | 24-10 |
| 23 | 5-17 | 6-17 | 15-10 | 20-41 | 22-41 | 24-11 |
| 24 | 5-16 | 6-16 | 15-10 | 20-43 | 22-43 | 24-13 |
| 25 | 5-15 | 6-15 | 15-10 | 20-44 | 22-44 | 24-14 |
| 26 | 5-14 | 6-14 | 15-10 | 20-45 | 22-45 | 24-15 |
| 27 | 5-12 | 6-12 | 15-10 | 20-47 | 22-47 | 24-17 |
| 28 | 5-11 | 6-11 | 15-10 | 20-48 | 22-48 | 24-18 |
| 29 | 5-10 | 6-10 | 15-10 | 20-50 | 22-50 | 24-20 |
| 30 | 5-09 | 6-09 | 15-10 | 20-51 | 22-51 | 24-21 |
| 31 | 5-08 | 6-08 | 15-10 | 20-52 | 22-52 | 24-22 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут. (Время летнее).**




## Мичтә пешергән каз

Гадәттә, авылда казны мичтә пешерәләр.

Казны чистартып юалар да турыйлар. Тавык йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләрне әрчеп юалар, эре итеп суган турыйлар, тоз, борыч сибеп, лавр яфрагы салып, барысын бергә аерым савытта әйбәтләп болгаталар. Аннары чуенга салып, бераз су, кирәгенчә каймак өстәп, капкачын ябалар һәм 2-3 сәгатька яккан мичкә пешерергә куялар.

## Төче коймак

Төче коймакны гадәттә тиз өстәл әзерләргә кирәк булганда пешерәләр. Аны табынга варенье, джем белән бирергә мөмкин.

2-3 литрлы савытка йомырка сыталар да, шикәр комы салып, әйбәтләп болгаталар (туглагыч белән болгатканда такын да яхшырак). Аннары сөт яисә сөт өсте, тоз, чәй содасы, бодай оны салып туглыйлар һәм коймак пешерәләр. Камырны әчегән сөткә изәргә дә була. Коймакны табага күп итеп май салып, ике ягы да кызарганчы пешерәләр.

1 кг бодай онына: 0,9-1,1 л. сөт, сөт өсте яки ачыган сөт, 4-5 йомырка, 60-70 г. шикәр комы, балкашык сода, кирәгенчә май һәм тоз.

## Сыер ите белән дөге тутырмасы

Симез сыер итенең сөяксез йомшак җирен суган белән ит тарткычтан чыгаралар, тоз, борыч сибеп, әйбәтләп болгаталар. Азрак сөт яисә салкын шулпа, пешермичә генә, я бүрттереп дөге салалар. Катнашма сыек булырга тиеш.

Эшкәртелгән эчәкнең өчтән ике өлешенә шул катнашманы тутыралар да ачык башын бәйләп куялар. Катнашманы эчәк тулганчы салырга ярамый, чөнки пешкәндә ярма бүртә һәм тутырма ярылып китәргә мөмкин.Әзер тутырманы уклауга бәйлиләр дә кайнап торган тозлы сулы кастрюльгә батыралар һәм 30-40 минут пешерәләр. Табынга кайнар килеш тә майлы табада ут өстендә яисә духовкада кыздырып алырга була.

Тутырма янына әйрән, салкын катык куялар, теләгән кешегә кайнар ит шулпасы бирәләр.

ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.

Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**